Чыганак: **Халык язучысы Гомәр Бәширов: буклет / Татарстан Язучылар берлеге; төз.Р.Аймәт; рәс.Й.Вәлиәхмәтов; З.Бәширов, А.Андронов, Р.Мөхәммәтҗанов фотолары. - Казан, 1996.**

Дөрес, без үткән гомер юлы төрлечәрәк — аныкы шомарак, минеке тайгакрак булды. Шулай ук күтәргән йөгебез дә бер үк түгел — аныкы авыррак, минеке җиңелрәк... (Сүз, билгеле, иҗади эшчәнлегебез турында бара.) Әмма юлыбызның кыйбласы бер иде: дөньяны гаделрәк, тормышны ялгансызрак, халкыбызны иманлырак итеп күрү... Шушы теләкләрнең соңгысы Гомәр абзый иҗатында аеруча тулы чагылды.

Әмирхан ЕНИКИ.

Гомәр абыйга 95 яшь... Бу — татар әдәбияты тарихында булмаган феномен. Ул әле төз гәүдәле, зиһенле, кешеләрне игътибар белән тыңлый белә торган карт. Озын гомер юлы узып, егерменче гасырның яшьтәше булып, туган халкы белән бергә атлаган бәхетле язучы ул. Заман сулышларын үзенә хас табигый-салмак, романтик-күтәренке һәм лирик-нәфис алым белән, кояшлы яңгыр шикелле шифалы һәм саф итеп, чишмә җыры итеп үзебезнең ана телебездә укучыга җиткерә алган язучы, Татарстанның халык язучысы — чыннан да бәхетле язучы ул.

Гариф АХУНОВ.

Гомәр ага үзенең әсәрләре кебек үк төпле кеше. Ул һәртөрле ыгы-зыгылардан югары була белә, үз өстенә чәчрәп кунганнар дәрәҗәсенә төшеп вакланмый, юк-бар бәхәскә катышмый...

Туфан МИҢНУЛЛИН.

Замандаш та, фикердәш тә була белгән, берничә дәверне каһарманнарча кичеп һәм кичереп, XX гасырны тулаем колачлап фикер йөрткән, күзгә туры карап киңәш биргән, гыйбрәт һәм сабырлык чыганагы булган талант иясе татар әдәбиятында, татар дөньясында бары тик бер генә. Ул — Гомәр Бәширов.

Ринат МӨХӘММӘДИЕВ.

Гомәр абый хатын-кыз язучыларга һәрвакыт хәер-хакта булды. Мин әдәбият мәйданына аяк баскан-да, ул Язучылар союзы рәисе иде, шул чакта ук мин аның үземә карата булган ярдәмчел җылы мөнәсәбәтен тоя идем. Иҗатымның беренче чорында өлкән язучылар, тәнкыйтьчеләр кайсы хаклы, кайсы хаксыз рәвештә мине бик нык тәнкыйтьләделәр. Арадан бер Гомәр абый гына ул тәнкыйтьләргә кушылмады, хәтта «Совет әдәбияты» журналындагы бер мәкаләсендә «Китмә сандугач»ны уңышлы җыр дип, минем иҗатымны яклап чыкты. Мин Гомәр абыйга бик рәхмәтлемен.

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА.

Гомәр абый Бәширов, гаять катлаулы егерменче гасырны буеннан-буена исән-имин үтүе белән бер бәхетле булса, тулы бер йөзъеллык тарихыбызны бик талантлы гәүдәләндергән каләм әһеле булуы сәбәпле тагы да сәгадәтле.

Фоат ГАЛИМУЛЛИН.

Иманым камил: килер бер көн һәм татарның зирәк баласы телебезнең тәме хакында укып туймаслык китап язар. Һәм ул үзенең бу әсәрендә олуг әдибебез Гомәр Бәширов әфсен өргән җөмләләргә кабат-кабат тукталыр.

Зөлфәт.

Татарстан Милли китапханәсендә сакланучы өч миллионнан артык китап арасында кулдан-кулга күчеп тузып-таушалып беткәннәре дә, еллар буе үз укучысын көтеп ятканнары да бар. Гомәр ага Бәшировның китаплары нәкъ менә шуларның беренчесенә, көн саен үз укучысы белән очрашу-аралашу бәхетенә ия булганнары рәтенә керә. Әдип иҗатына шуннан да зуррак мәртәбәнең, халык мәхәббәтеннән дә олырак бәянең булуы мөмкин микән?!

Разил ВӘЛИЕВ.